**ГЛАВА**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2025 Исәнбай авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы « Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 1нче этабын 2025 елның 30 октябрендә 10сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 2нче этабын 2025 елның 30октябрендә 11әгать 00 минутка билгеләргә.

3. 3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:
-1 этап: Совет урамы, Хезмәт урамы, Елга урамы, Ленин урамы,

-2 этап: Мәктәп урамы, Яр буе урамы, Яшьләр урамы, Кирпеч урамы, Октябрь урамы,

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

1. Үләт базын киртәләү.
2.Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр челтәрләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау
2.1. Фонарьлар, лампалар, урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алыштыру; хезмәт килешүе буенча электрикка хезмәт хакы түләү һәм башка чаралар.

3. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
3.1. Сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, сууткәргеч челтәрен ремонтлау, торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

4. Торак пуктны төзекләндерү:
4.1 Трактор тоту һәм хезмәт күрсәтү, дизель ягулыгы, дизель мае, запас частьләр сатып алырга; чүп үләннәрен чабарга, урамнарны кардан чистартырга, хезмәт килешүе буенча трактористка хезмәт хакы түләү; роторлы чапкыч сатып алу, төзекләндерү буенча башка чыгымнар.
4.2 Паркны төзекләндерү, волейбол мәйданчыгы урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Исәнбай авылы, Совет урамы, 79нчы йорт, авыл мәдәният йорты адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының  Исәнбай авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм  "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең  Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы                Р.Р.Мөхәммәдиев